Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Колай авыл җирлеге башкарма комитеты

Колай авыл җирлеге башкарма комитеты

# КАРАРЫ

10 ноябрь, 2025 ел № 20

«Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 17 мартындагы 5 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Колай авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыру турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Колай авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. «Белешмәләр (өземтәләр) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге башкарма комитеты карарына (башкарма комитетының 2022 елның 17 мартындагы 5 номерлы карарына (2022 елның 31 октябрендәге 19, 2023 елның 16 июнендәге 28 номерлы башкарма комитет карарлары белән расланган үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.5. нче бүлекнең 2.5.1 пунктының 6 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«6) дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен бирү һәм аларны эшкәртү кирәк булган очракта һәм федераль закон нигезендә мондый шәхси күрсәткечләрне эшкәртү күрсәтелгән затның ризалыгы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин булса, дәүләт яисә муниципаль хезмәтне алуны сорап мөрәҗәгать иткәндә мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән затның яисә аның законлы вәкиленең күрсәтелгән затның шәхси күрсәткечләрен эшкәртүгә ризалыгын алуын раслый торган өстәмә документлар тапшыра. Ризалык алуны раслый торган документлар шул исәптән электрон документ рәвешендә дә тапшырылырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси белешмәләре федераль башкарма хакимият органнарының, бюджеттан тыш дәүләт фондлары органнарының, Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнарының, шулай ук җирле үзидарә органнарының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча вәкаләтләрен үтәү өчен бердәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә бирелгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә мондый белешмәләр күрсәтелмичә, мондый затның

яисә аның законлы вәкиленең ризалыгын алу күрсәтелгән максатларда мондый затның шәхси мәгълүматларын эшкәртү таләп ителми.».

1. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Питрәч муниципаль районы
Колай авыл җирлеге башлыгы Н.В.Поповская

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КУЛАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1633605809